ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр хакыннан чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәй датасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 402 статьясы, “Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 12 һәм 85 статьяларына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү һәм “Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында” Россия Федерациясе Законының үз көчен югалтуын тану хакында” 2014 елның 4 октябрендәге 284-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлеше нигезендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр хакыннан чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәй датасын 2015 елның 1 гыйнварыннан билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 30 октябре
№ 82-ТРЗ